| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Кавзияковского сельского<br>поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Кәүҗияк авыл җирлеге советы |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 сентябрь № 16

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә, Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ.:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
"Сез 2018 елда Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп);
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру ; ;
- җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

«ӘЙЕ, ЮК».

2.Әлеге карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Кәүҗияк авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.А.Хөснетдинов